**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 12 мартындагы 762 номерлы карары**

## 2026 елга гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле милек хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясы, 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы «Гражданнарның Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль яллау килешүләре буенча торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы Татарстан Республикасы Законы, әлеге законның кушымтасында бирелгән Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гражданин милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек хакын билгеләү методикасы нигезендә, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге уставының 40 статьясына таянып, **карар бирәм**:

1. 2026 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек хакының чиге:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 2 756 628,0 сум;

1.1.2. ике кешелек гаилә өчен – 5 513 256,0 сум;

1.1.3. өч кешелек гаилә өчен – 8 269 884,0 сум;

1.1.4.  дүрт кешелек гаилә өчен – 11 026 512,0 сум;

1.1.5. биш кешелек гаилә өчен – 13 783 140,0 сум;

1.1.6. алты кешелек гаилә өчен – 16 539 768,0 сум;

1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен – 19 296 396,0 сум;

1.1.8.сигез кешелек гаилә өчен – 22 053 024,0 сум;

1.1.9. тугыз кешелек гаилә өчен – 24 809 652,0 сум;

1.1.10. ун кешелек гаилә өчен – 27 566 280,0 сум;

1.1.11. унбер кешелек гаилә өчен – 30 322 908,0 сум;

1.1.12. унике кешелек гаилә өчен – 33 079 536,0 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме – 48 515,0 сум.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре башлыклары Р.Х.Шәмсетдиновка, А.И.Салиховка, В.В.Жаворонковка һәм Р.Р.Фәтхетдиновка гражданнарны социаль яллау килешүләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрен файдаланырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**